| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25 январь 2016 ел. № 4

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Әлмәт авыл җирлеге Уставының 11 ст., Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итә.:

1."2016 елда Әлмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешегә 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан тыш, сез риза буласызмы?:

1) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

2) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;;

3) җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;;

4) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

5) көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру;

6) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә

7) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

« ЮК» «ӘЙЕ».

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Д. Ә. Газизов